Казан шәһәре Совет районы “күп профильле 181 нче мәктәп”

№7 март 2019 ел

# «Күкнең җиденче катында»

## Тантаналы линейкалар



21 нче мартта мәктәбебездә III чирек бетү уңаеннан тантаналы линейкалар булды. Олимпиадаларда, конкурсларда, конференцияләрдә җиңүчеләргә диплом һәм грамоталар тапшырылды. Тәрбия эшләре буенча директор урынбасары Михайлова Гөлнара Миннегали кызы балаларга юл йөрү кагыйдәләре, әдәплелек кагыйдәләре турында, язгы бозга керергә ярамаганлыгы турында искә төшерде.

**Мельникова Аделина, 5Д сыйныфы**

***

23 нче март көнне мәктәп яны лагере эшен башлады.

Лагерьны ачу зарядкадан башланды. Балалар бу көнне “Куркынычсыз интернет” төшенчәсе белән таныштылар, рәсем бәйгесендә катнаштылар. Балаларга күңелле булды. Җиңүчеләр дә билгеләнде.

Икенче көнне лагерьда “Фәнни шоу-космик температура, кайнар һәм салкын тәҗрибәләр” программасы белән “Реаль астрономия” кунакта булды.

Өченче көнне балалар "Юл йөрү кагыйдәләре илендә мажаралар"дигән мавыктыргыч спектакль карадылар.

Дүртенче көнгә иртә күңелле дискотека белән башланып китте. Төштән соң балалар ЮХИДИ инспекторы белән очраштылар. Юл йөрү кагыйдәләрен кабатладылар!

**Вәлиева Диләрә,5 Е сыйныфы**

***

## "Балалар хәрәкәте маршруты буенча җәяүле экскурсия"

22 нче март көнне 3нче сыйныф укучылары, ЮИД отряды һәм ата-аналар патруле белән берлектә, "Балалар хәрәкәте маршруты буенча җәяүле экскурсия" һәм “Тукта! Сиңа куркыныч яный!” исеме астында рейдлар узды. Катнаштылар: Кабирова Л.А. - Россия Эчке эшләр министрлыгының Казан шәһәре буенча идарәсенең "Гвардейский" ПДН хезмәткәре Мөдәрисова Л.М. - "юл хәрәкәте иминлеге" ДБУ Казан шәһәрендәге территориаль идарәне профилактикалау бүлегенең әйдәп баручы белгече.



Юл йөргәндә сак булырга һәм юл йөрү кагыйдәләрен үтәргә чакырабыз!

**Мәхмүтова Мәдинә, 5Е сыйныфы**

***

## “Матурлыкка юл” бәйгесе

14 мартта 8 В сыйныфы укучысы Кәлимуллина Диана “Матурлыкка юл” район бәйгесендә катнашып II нче урынны яулады. Диана үзен һәр яктан күрсәтте: җырлады, уйнады, бавырсак пешерде, хәтта дизайнер ролендә дә сынатмады.

**Мәхмүтова Мәликә, 5Е сыйныфы**

## Махсус хәбәрләр

22 нче март көнне мәктәбебезнең яшь гаскәриләре 161 нче мәктәптә “Тезелү смотры” бәйгесендә катнашып 15 мәктәп арасында 5 нче урынны яуладылар.

Командирлар арасында Гәрәев Әмирхан 1 нче урынга чыкты.Афәрин!

**Хөснетдинова Камелия,**
**5 Г сыйныфы**

***

## “Чиксез балачак"бәйгесе

"Чиксез балачак" бәйгесе дәвам итә...
Бәйгенең максатлары һәм бурычлары:
- Балаларны мәдәнияткә, сәнгатькә тарту.
-Аларның сәләтен ачу һәм үстерүгә булышлык күрсәтү.

Бәйге 2019 нчы елның 1 гыйнварыннан алып 1 июньгә кадәр барачак. Әлеге конкурста 3 яшьтән алып 14 яшькә кадәр балалар катнаша ала. Конкурста катнашу өчен тутырылган анкета һәм рәсемнәрне оештыручы комитетка җибәрергә кирәк. 2019 нчы елның 1-3 апрель көннәрендә Оргкомитет аларны Бөтендөнья татар конгрессы Башкарма комитетының рәсми сайтына урнаштырачак. 3нән алып 30 апрельгә кадәр интернет тавыш бирү оештырылачак. 5-8 май көннәрендә конкурска нәтиҗәләр ясалачак. Җиңүчеләргә финалда катнашу өчен чакырулар җибәреләчәк.

Әлеге бәйгедә катнашучы укучыларыбыз:Абашаев Б (5Е),Мингәрәева Р (4В), Данилина З(8В), Кузнецова А.(8В),Есенская А(6В), Морозова М(6Г), Корчагина Я(8А), Аспенников Д.(8Б), Вильданова Д(5Б) эшләре нәтиҗәле булыр дип ышанып калабыз.Аларга уңышлар телибез, җиңү яулауларын теләп калабыз.

**Хәйриев Самат,**
**5Д сыйныфы**

***

## “Озын тәнәфес” бәйгесе дәвам итә.

Мәркәзебез Казан шәһәрендә “Озын тәнәфес” бәйгесе 2008 нче елдан бирле уздырыла.
Фестиваль өч этапта оештырыла.

Беренче сайлап алу туры мәктәп эчендә, икенчесе район күләмендә узды инде. Өченчесе исә шәһәр дәрәҗәсендә узачак. Мәктәбебез ике турда җиңү яулап 3 нче турга үтте.
Финалистларны 4 юнәлештә сайлап алдылар: җыр, бию, театр һәм үзенчәлекле номерлар.Төп бүләк: 1млн. акча. Ул акча уку йорты инфраструктура үсеше өчен тотылырга тиеш.

Бу чара беренче тапкыр 2008 елда Казан мэры тәкъдиме белән оештырылды. Ул мәктәп укучыларын шәһәрнең иҗади тормышына җәлеп итүдә мөһим роль үти. “Озын тәнәфес” фестивалендә чыгыш ясаган яшь артистлар киләчәктә “Йолдызлык” кебек яшьләр фестивалендә катнаша ала.
Хәзерге вакытта Россия Яшьләр берлеге тарафыннан “Озын тәнәфес” фестивален Россия күләмендә оештыру мәсьәләсе карала.

**Вәлиева Диләрә,**
**5Е сыйныфы**

***

## “Саннар дәресе”

12 нче март көнне мәктәбебез укучылары “Саннар дәресе” ндә катнаштылар.

Нәрсә соң ул “Саннар дәресе”?

“Саннар дәресе” –төрле яшьтәге укучылар уен формасында программалаштыру нигезләре һәм сан технологиясе белән танышалар.

“Саннар дәресе” февраль – май ае буенча бара, ул айга бер уздырыла.

Һәр дәрес билгеле бер темага багышлана “Кадрлар һәм белем” милли программасы кысаларында саннар турында белемнәрне тирәнәйтү максатыннан уздырыла.

“Саннар дәресе” Министрлыклар тарафыннан оештырыла.

**Мельникова Аделина,**
**5Д сыйныфы**

***

## Казан университеты тарихы театрына экскурсия

7 “Б” сыйныфы укучыларының каникуллары Казан университеты тарихы белән танышудан башланды.

Балалар КФУ тарихы музеенда булдылар, анда үзләре өчен югары уку йорты белән генә түгел, аларның көндәлек тормышы белән дә бәйле кызыклы фактларны белделәр. Шулай итеп, укучылар аспиринның ничек барлыкка килүе, видеомагнитофон уйлап табу, тукымаларның буяулары һәм башка күп нәрсәләр турында белделәр. Экскурсия шулкадәр кызыклы булды, балалар моның белән генә чикләнеп калмаска, тиздән университетка башка кызыклы экскурсияләргә барырга карар кылдылар.

## Иҗат җимешләре

### Ямьле яз

Мин язны бик яратам. Язын үлән үсә башлый, агачлар чәчәк аталар, кошлар үз ояларына кайталар, матур итеп сайрыйлар, аюлар йокыларыннан уяналар.

Яз көне бакчада да эшләр күбәя. Төрле яшелчәләр, чәчәкләр утыртабыз. Гомумән, ямьле яз миңа бик ошый.

**Вәлиева Диләрә,**
**5Е сыйныфы**

***

### Ягымлы яз

Яз килә. Нинди ямьле мизгел ул! Тирә-якта кар эри, боз китә. Челтер-челтер итеп сулар ага, тамчылар тама. Яз көннәре бик күңелле. Безнең дусларыбыз-сыерчыклар да җылы яктан очып кайталар.

Кояш та безгә елмаеп карый. Тирә-як кышкы йокыдан уяна. Яшел бөреләрен төртеп ямь- яшел үлән чыга, бөреләр бүртә. Бөтен дөнья тәмле хуш ис белән тула. Миңа ягымлы яз бик ошый.

**Мельникова Аделина,**
**5Д сыйныфы**

***

### Көтеп алган язым

Кышның салкыннардан соң мин язны сагынып көтеп алам. Яз- табигатьнең кышкы йокыдан уяну вакыты. Яз кояшы елмаеп карау белән бөтен табигать кышкы йокысыннан уяна башлый. Язгы җылы җил агачтагы яшь бөреләрне уята. Тиздән алар хуш исле яшел яфраклар ярырлар. Бөтен дөньяга ямь биреп торырлар. Яз аен мин бик яратам!

**Хәсәнова Адилә,**
**5 Е сыйныфы**

***

## Котлыйбыз

Хөрмәтле хатын-кызлар!

Сезне чын күңелдән 8 нче март-Халыкара хатын-кызлар көне белән котлыйбыз. Сезгә озын гомер, сәламәтлек, бәхет шатлык телибез һәрвакытта көләч йөзле, күркәм булып калыгыз.

Бәхеткә- шатлыкка күмелеп,
Һәрвакыт елмаеп һәм көлеп
Кадергә, хөрмәткә төренеп,
Яшәгез мәңгелек нур булып.

### Нәүрүз килә...

Нурларын көннән-көн матурырак чәчкән кояшлы зәп-зәңгәр күк йөзе белән яз килә. Яз ае безгә бер зур бәйрәм-Нәүрүз бәйрәмен алып килә. Бу бәйрәмне безгә борынгы бабаларыбыз биреп калдырган. Кышлар үтеп, табигать җанлангач, көннең төнгә куып җиткән вакытында, Кыш бабайның чәчләре кар сулары булып акканда, безнең төрки бабаларыбыз Язны - Нәүрүзбикәне каршылаганнар.

Бу көнне алар үзләренең изге теләкләрен Нәүрүзбикәгә әйтеп калырга ашыкканнар.

Нәүрүз-Яңа көн дигәнне аңлата. Көнчыгыш календаре буенча бу-Яңа елны каршылау бәйрәме.

Көннәр җылы, күктән алсу
Нур сибеп кояш көлә.
Җәйге шатлык, көзге бәхет,
Яз белән бергә килә.
Нәүрүз котлы булсын!
Тормыш түгәрәк булсын!
Мал-туарыбыз артсын!
Игеннәребез уңсын
Күкәй кебек тук булсын!
Елларыбыз тыныч торсын,
Күкләребез аяз булсын,
Изге догаларыбыздан аермасын,
Мәңге шат яшик дуслар!

***

## Ниһаять, март ае да килеп җитте.

Март ае.Яз! Ямьле яз аеның беренче ае.

Яз ае күңелле ай.Табигать уяна, кошлар кайта, кояш җылыта.

Кешеләрдә язгы өметләр уяна.

Укучылар да март аен түземсезлек белән көтә.Тиздән язгы каникуллар башланачак...

## Язгы каникулым.

Мин язгы каникулда дәү әнием белән дәү әтием янына авылга кайтырга уйлыйм.

Ул авыл Казаннан 40 чакрым ераклыкта урнашкан Шәле авылы.

Авыл табигатен язып китсәң...

Матур аланнары, хуш исле урманнары, зәңгәр елга-күлләре искиткеч ямьле. Рәт-рәт тезелеп киткән авыл йортлары, мәдәният үзәге, мәктәп һ.б. Аларны санап бетереп булмый!

Дәү әниемнәр авылыбызның иң югары очында, Өчиле урамында яшиләр.

Каникуллар җитү белән мин алар янына ашкынам. Аларга хуҗалык эшләрендә булышырга тырышам, эшләремне төгәлләгәч, якын дусларым янына чыгам. Без бергәләп уеннар уйныйбыз, яңалыклар белән уртаклашабыз.

Менә шулай каникуллар сиздермичә генә уза да китә. Бик күп тәэссирләр белән тулы кала ул миндә.

Авылга кайтам мин

Ашкынып, сагынып...

Хәлләр белешергә,

Әбием, бабам белән күрешергә.

Сагындыра авыл табигате.

Онытыла дөнья мәшәкате.

Искә төшә нәни чакларым,

Йөгереп, уйнап йөргән вакытым.

Әй, дусларым, сезгә тәкъдим итәм,

Кайтыгыз, сез, гүзәл табигатле,

Саф һавалы авыл ягына.

Килеп җитте инде ямьле язлар,

Килеп җитәр эссе җәйләр дә.

Язгы матурлыкны күреп калыгыз,

Авылларга тизрәк ашыгыгыз!

**Хәсәнова Адилә,**

**5 Е сыйныфы**

**Редакциянең адресы:**
420101, Казан шәһәре,
Тулпар урамы, 2
Тел. 89050229576

**Тираж** – 50 экз.

**Баш мөхәррир һәм дизайнер:**
Корчагина Яна

**Редколлегия әгъзалары:**
Мәхмүтова Мәдинә, Хәйриев Самат, Вәлиева Диләрә, Мельникова Аделина, Мәхмүтова Мәликә, Хөснетдинова Камелия

***

Балаларның көлешкәнен
Ишетсен Җир, тыңласын Җир!
Балаларның көлүеннән
Берчакта да тынмасын Җир!

Ә балалар көлә икән
Илебездә, Җиребездә,
Димәк, Җир дә исән әле,
Имин, димәк, Илебез дә!

**Р. Миңнуллин**